ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш, Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш., Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 111 от «20» 03 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 7 октябрендәге «Яңа редакциядә муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 331 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, “Россия Федерациясе Җир кодексына һәм “Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү һәм “Россия Федерациясе Җир кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” Федераль законның 34 статьясындагы 7 өлешенең үз көчен югалтуын тану хакында” Федераль законның 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында” 2024 елның 28 декабрендәге 538-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 7 октябрендәге «Яңа редакциядә муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 331 номерлы карарына (алга таба -Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар белән расланган 1, 2 кушымталарның 2.8.2.1 пунктындагы 13 пунктчада “бастырып чыгарылган һәм” сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге Караның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары Р.М.Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче Р.М.Гарипов

0000012642